**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Иске Борындык авылында гражданнар җыены карары**

16.11.2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Иске Борындык авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Боерган авыл җирлегенең Иске Борындык авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Иске Борындык авылында юлларны ремонтлауга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Боерган авыл җирлегенең Иске Борындык авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Боерган авыл җирлеге башлыгы _________ И.В. Малышева

Халык җыены секретаре _________ О.А. Малышева